**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
Село Янурусово, улица Ленина, дом 43в, 423370
Телефон 4-10-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
Ленин урамы,43 в йорт, Янурыс авылы, 423370
Телефон:
4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

**5 нче карар**

Янурыс ав. «11» апрель, 2017ел.

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән) нигезендә, ТР Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына Сарман районы прокуратурасының 2016 елның 13 февралендәге 02-07-01/2017 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Янурыс авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман районы прокуратурасының 2016 елның 13 февралендәге 02-07-01/2017 номерлы протесты белән «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына килешергә.

2. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципларын регламентлаучы гамәлдәге законнар нигезендә туры китерергә.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне хупларга

4.Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау эшен дәвам итәргә, аннары Яңурыс авыл җирлеге Советы утырышына карау белән.

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеменә язмача рәвештә, ФИО, туган елы, яшәү урыны адресын күрсәтеп: Янурыс авылы, Ленин урамы 43а адресы буенча җибәрелә дип билгеләргә.

6. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Яңурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча 2017 елның 25 апрелендә 16.00 сәгатьтә Янурыс авылы мәдәният йорты, Ленин 43а ур. залында гавами тыңлаулар билгеләргә.

7. Региональ экспертизаны уздыру өчен карар проектын Сарман районы прокуратурасына җибәрергә.

8. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Янурыс җирлеге башлыгы А.А.Мөхәммәдиева

2017елның 11 апрелендәге 5 нче
Янурыс авыл җирлеге Советы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Яңурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1)25 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә**
7) Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

- үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

- җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.

8) Муниципаль вазыйфаны, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) биләгән зат мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган очракта, күрсәтелгән зат үзенә караган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга тиеш.

**25 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

6. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт

вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

**3) 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3, 4 өлешләр өстәргә:**

3. Җирлек вәкиленең вәкаләтләре әлеге Уставның 35 статьясында каралган нигезләрдә, шулай ук депутат этикасы кагыйдәләрен, депутат статусы турындагы нигезләмәдә беркетелгән депутатның йөкләмәләрен бозудан соң вакытыннан алда туктатыла.

4. Җирлек вәкиле депутат җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының кимендә өчтән бере санында Башлык инициативасы буенча яисә депутатлар төркемен куллану буенча кабул ителә торган җирлек Советы карары белән теләсә кайсы вакытта да кире алынырга мөмкин.
Җирлек советы депутатларының чакыртып алу турындагы карары җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санында билгеләнгән тавышларның өчтән икесе тарафыннан кабул ителә.

**4) 35 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:**

4. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш.

**38 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән әлеге Устав белән;